**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“29” ноябрь 2020 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Югары Көек торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек авылы территориясендә 2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Югары Көек торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Территорияне төзекләндерү һәм чистарту:

- агач һәм куакларны кисү, Югары Көек авылы территориясен чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү
- урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү (лампочкаларны, үткәргечләрне ремонтлау, алыштыру) һәм лампочкалар сатып алу.

2) Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

- зиратны төзекләндерү (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү.

3) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- Югары Көек авылында су башнясы өчен насос сатып алу;
- Югары Көек авылындагы су башнясына будка урнаштыру өчен төзелеш материаллары сатып алу, хезмәтләр һәм эшләр өчен түләү;
- Янгын гидранты өчен колонка сатып алу.

4) Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Югары Көек авылында урам юллары өслекләрен ремонтлау һәм төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, ташу, аларны җәю, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү)”;
- юл билгеләрен сатып алу һәм урнаштыру мәсьәләләрен кабул итәргә.

Экономия ясалган очракта, аерым мәсьәләләр буенча Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә мәсьәләләрен кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Югары Көек авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Түбән Көек авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Галиәхмәтов Д.М.